ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 7.3 һәм 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 17 апрелендә
кабул ителде

## 1 статья

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7.3 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән органнар исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне түбәндәгеләр карый:

1) Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге баш дәүләт инспекторы, аның урынбасарлары;

2) Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге өлкән дәүләт инспекторлары;

3) Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге дәүләт инспекторлары.»;

2) 8.1 статьяның 8 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2017 ел, 27 апрель
№ 26-ТРЗ